КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 11 ноябрь г.Казань № 864

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2017 елга, 2018 һәм 2019 еллар план чорына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга медицина ярдәмен түләүсез күрсәтү буенча дәүләт гарантияләре программасын раслау турында» 2016 ел, 29 декабрь, 1044 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2017 елга, 2018 һәм 2019 еллар план чорына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга медицина ярдәмен түләүсез күрсәтү буенча дәүләт гарантияләре программасын раслау турында» 2016 ел, 29 декабрь, 1044 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Программаны тормышка ашыруда катнашучы һәм Программа кысаларында социаль ярдәм чаралары күрсәтүче, гарантияләр, хокуклар һәм ташламалар бирүче медицина оешмаларына социаль ярдәм чаралары күрсәтү, гарантияләр, хокуклар һәм ташламалар бирү турындагы мәгълүматны Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасында Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм күләмдә һәм Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасы операторы тарафыннан билгеләнгән форматлар нигезендә бирүне тәэмин итәргә;

бу карар нигезендә социаль яклау (ярдәм) чаралары күрсәтү, гарантияләр, хокуклар һәм ташламалар бирү турындагы мәгълүмат Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырыла. Әлеге мәгълүматны Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасына урнаштыру (аннан алу)

«Дәүләт социаль ярдәме турында» 1999 ел, 17 июль, ФЗ-178 нче Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла;

Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланучылар бу карарның 2 нче пунктындагы беренче абзацта күрсәтелгән мәгълүмат белән тәэмин итүчеләр, шулай ук гражданнар булып тора. Гражданнарның мәгълүмат системасыннан файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итү бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша гамәлгә ашырыла.».

2. Бу карар 2018 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\864.docx